ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
**ЗАКОНЫ**

# “Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы тарафыннан
2017 елның 17 апрелендә
кабул ителде

**1 статья**

“Татарстан Республикасында күпфатирлы йортларда гомуми мөлкәткә капиталь ремонт ясауны оештыру турында” 2013 елның 25 июнендәге 52-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законына (Татарстан Дәүләт Советы Җыелма басмасы, 2013, № 6 (II өлеш); 2014, № 5, № 11 (I өлеш); 2015, № 12 (I өлеш); 2016, № 1 – 2, № 10) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1) 3 статьяның 1 өлешенә түбәндәге эчтәлекле $13^4$ пункт өстәргә:

“$13^4$) аварияләр, табигый яисә техноген характердагы башка гадәттән тыш хәлләр килеп чыккан очракта, Россия Федерациясе Торак кодексының 189 статьясындагы 5 өлешенең 1 – 4 пунктларында каралган мәсьәләләр буенча карар кабул итү тәртибен билгеләү;”;

2) 4 статьяның 2 пунктында “каралган очракларда” сүзләрен “каралган очракларда һәм срокларда” сүзләренә алмаштырырга;

3) 8 статьяның 1 өлешендә:

а) 1 пунктка “, шулай ук комплекста индивидуаль җылылык пунктлары (ИҖП) җайланмаларын һәм, булган очракта, басымны арттыра торган насос җайланмаларын урнаштыру, ремонтлау яисә алмаштыру” сүзләрен өстәргә;

б) 7 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“7) күпфатирлы йортның нигезен, шулай ук төп стеналарын, катлары арасындагы плитәләрне, балкон плитәләрен һәм башка плитәләрне, төп колонналарын һәм бүлүче башка төп конструкцияләрен ремонтлау һәм (яки) ныгыту;”;

в) 8 пунктта “подъездларны” сүзеннән соң “, аерым милекчеләрнеке булмаган һәм урыннар милекчеләренең социаль-көнкүреш ихтыяҗларын канәгатьләндерү өчен каралган башка бүлмәләрне” сүзләрен өстәргә;

4) 12 статьяда:

а) 1 өлештә:

2 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

“2) капиталь ремонт өчен кертемнәр буларак күчерелгән акчалар күләме турында мәгълүмат;”;

түбәндәге эчтәлекле $2^1$ һәм $2^2$ пунктлар өстәргә:

“$2^1$) капиталь ремонт өчен кертемнәр буларак кергән акчалар күләме турында мәгълүмат;

$2^2$) махсус счеттан капиталь ремонтка тотылган акчалар күләме турында мәгълүмат;”;

түбәндәге эчтәлекле 4 пункт өстәргә:

“4) капиталь ремонт уздыруга заем шартнамәсе һәм (яисә) кредит шартнамәсе төзү турында, аларның күчермәләрен кушымта итеп биреп, мәгълүмат.”;

б) түбәндәге эчтәлекле $2^1$ өлеш өстәргә:

“$2^1$. Капиталь ремонт өчен кертемнәр буларак күчерелгән акчалар күләме турында белешмәләр Россия Федерациясе Торак кодексының 175 статьясындагы $3^1$ өлешендә күрсәтелгән вәкаләтле зат тарафыннан махсус счет хуҗасына ай саен, хисап аеннан соң килә торган айның бишенче числосына кадәр, шул исәптән электрон рәвештә дә, Татарстан Республикасы дәүләт торак күзәтчелеге органы билгеләгән рәвештә тапшырыла.”;

в) 3 өлештә “2 һәм 3 пунктларында” сүзләрен “2 – 4 пунктларында” сүзләренә, “беренче числосына кадәр” сүзләрен “10 нчы числосына кадәр” сүзләренә алмаштырырга.

**2 статья**

Әлеге Закон рәсми басылып чыккан көненнән үз көченә керә.

Татарстан Республикасы
Президенты                                                                 Р.Н. Миңнеханов

Казан,Кремль
2017 ел, 27 апрель
№ 25-ТРЗ